ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.02.2019 Олы Кайбыч авылы № 58

**2016нчы елның 30нчы декабрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында расланган 543нче номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

2017нче елның 27нче ноябрендә кабул ителгән 355-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2006 елның 2 маенда чыккан 59-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә, 2018нче елның 27нче декабрендә чыккан 528-ФЗномерлы «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясе территорияләрендә өстенлекле социаль –икътисадый үсеш турында» Федераль законының 22нче статьясының 2нче бүлеге 2нче пункты үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законының миграция өлкәсендә һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп кору" федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛА:**

1. 2016нчы елның 30нчы декабрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында расланган 543нче номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктының 3нче абзацын түбәндәге редакциядә шәрехләргә:

«Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгать, 2006 елның 2 маенда чыккан 59-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә гражданин һичшиксез үз фамилиясен, исемен, әтисенең исемен(соңгысын – булган очракта),

җавап, мөрәҗәгать бүтән берәүгә җибәрелү турында хәбәр җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтергә тиеш. Мондый мөрәҗәгатькә гражданин электрон формада тиешле документлар һәм материалларны өстәргә мөмкин»;

1.4 пунктында "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, контроль, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органы" сүзләрен «эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.13 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«1.13. язма мөрәҗәгать эчтәлеге гариза, тәкъдим яки шикаять асылын билгеләргә рөхсәт итмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен аларның компетенцияләре нигезендә Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затларга җибәрелми , бу турыда мөрәҗәгать теркәлүдән алып 7 көн эчендә аны җибәргән гражданинга хәбәр ителә»;

2.15 пунктының 3нче абзацын түбәндәгечә шәрехләргә:

«Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресына, һәм җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма рәвештә җибәрелгән мөрәҗәгатькә язма рәвештә, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресына юллана. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка килгән, чикләнмәгән затлар даирәсенең мәнфәгатьләренә кагыла торган гариза, тәкъдим яки шикаять язылган мөрәҗәгать, аерым алганда, чикләнмәгән затлар даирәсенең мәнфәгатьләренә кагыла торган суд карары аклана торган мөрәҗәгать, шул исәптән суд карарын яңадан карау тәртибен аңлатучы җавап, 2006 елның 2 маенда чыккан 59-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы Федераль законының 2нче өлеше 6нчы статьясы нигендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион –телекоммуникацион Интернет челтәрендәге түбәндәге веб-адрес буенча урнашкан рәсми сайтка урнаштырылырга мөмкин: http:// kaybici.tatarstan.ru;

2.15нче пунктны түбәндәге эчтәлекле 4нче абзац белән тулыландырырга:

«Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка андагы сорауга җавап Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Тәртибенең 2.15пункты 3нче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион –телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнашкан рәсми сайтка куелган язма мөрәҗәгать килгән очракта, мөрәҗәгать юллаган гражданинга, мөрәҗәгать теркәлүдән алып 7 көн эчендә мөрәҗәгатьтәге сорауга җавап бирелгән “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә , шул ук вакытта суд карарын яңадан карауны сораган мөрәҗәгать кире кайтарылмый».

2. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районының информацион – телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адрес

буенча урнашкан рәсми сайтында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Н. Макаров**